| ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ<br>РЫБНО-СЛОБОДСКОГО<br>МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА<br>РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН | ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ<br>БАЛЫК БИСТӘСЕ<br>МУНИЦИПАЛЬРАЙОНЫНЫҢ<br>БАШКАРМА КОМИТЕТЫ |
|---|---|

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

29.12.2021 Балык Бистәсе штп №291пи

Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 маендагы 111пи номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Россия Федерациясе субъектларында инвестицион климат торышының милли рейтингы күрсәткечләре нигезендә Татарстан Республикасының инвестицион климат торышын яхшырту чараларын гамәлгә ашыру турында» 2001 елның 21октябрендәге 991 номерлы карары нигезендә, "Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында" 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 1 пунктының 19пунктчасына таянып, КАРАР БИРӘМ:

1. Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитетының 2021 елның 28 маендагы 111пи номерлы карары белән расланган җир эшләрен башкаруга ордер (рөхсәт) бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына түбәндәге үзгәрешләр кертергә.

1.1. 2.5.2 пунктының "д" пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"д) җир асты коммуникацияләре, корылмалары, шулай ук җир кишәрлекләре хуҗалары булган кызыксынган оешмалар белән (челтәр оешмалары тарафыннан башкарыла торган энергия кабул итү җайланмаларын технологик тоташтыруны гамәлгә ашыру очракларыннан тыш) килештерү».

2.Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы»нда http://pravo.tatarstan.ru адресы буенча һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районының рәсми сайтында http://ribnaya-sloboda.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балык Бистәсе муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктура үсеше буенча урынбасары Д.Н.Ризаевка йөкләргә.

Җитәкче Р. Л. Исланов